Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2021 елның 31 мае №27

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге Советының 2018 елның 24 сентябрендәге 100 номерлы карары белән расланган « Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына территорияләрне комплексло үстерүне тәэмин итү максатларында үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 7 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге советы карары белән расланган « Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендәге 6 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 12 статьяда:

өченче абзацта әлеге статьяның дүртенче абзацында билгеләнгән очраклардан тыш.» сүзләрен өстәргә,

түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче абзац өстәргә:
«Территорияне комплексле үстерү турындагы карар кабул ителүгә бәйле рәвештә җирлекнең генераль планына үзгәрешләр әзерләнгән очракта, иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар территорияне комплексле үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин.»;

дүртенче, бишенче һәм алтынчы абзацларны бишенче, алтынчы һәм җиденче абзацлар дип санарга.

3) 13 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, Октябрь ур., 65 йорт ( администрация бинасы)

- ТР, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, 2 нче Октябрь ур., 50 нче йорт ( мәдәният йорты)

шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга (https://kamskoye-ustye.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кама Тамагы муниципаль районының
Тәмте авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районының
Тәмте авыл җирлеге Советы рәисе И.А.Зиновьев